ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ПОДЛЕСНО-ШЕНТАЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРМАН АСТЫ ШОНТАЛЫСЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.06.2019 **с. Подлесная Шентала** №62

**“Күчемсез милек объектына адрес бирү, аны үзгәртү һәм бетерү кагыйдәләрен раслау турында”гы Татарстан Республикасы, Алексеевск муниципаль районы, Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге башкарма комитетының 27 август, 2015 ел, 15 нче Карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Гамәлдәге законнарга, шул исәптән “Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү һәм аларның көчләре югалган дип тану турында”гы 21 декабрь, 2018 ел, 1622 нче Карары нигезләмәләренә туры китерү максатында

**карар бирәм:**

1. “Күчемсез милек объектына адрес бирү, аны үзгәртү һәм бетерү кагыйдәләрен раслау турында”гы Татарстан Республикасы, Алексеевск муниципаль районы, Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге башкарма комитетының 27 август, 2015 ел, 15 нче Карарына түбәндәге эчтәлектәге үзгәрешләрне кертергә:

5 нче абзацның 2 нче пунктындагы “коммерциянеке булмаган бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача берләшмәләре урнаштыру территорияләре” дигән

сүзләрне “Гражданнар үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яки яшелчәчелек

алып бара торган территория” дигән сүзләргә алмаштырырга;

3 нче абзацның 29 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Коммерциянеке булмаган бакчачылык яки яшелчәчелек әгъзалары исеменнән гариза белән андый ширкәт әгъзаларының гомуми җыелышы карары белән кабул ителгән әлеге гаризаны бирергә вәкаләтле ширкәт вәкиле мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр Порталында җирлек сайтында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге бинасында махсус мәгълүмат стендында халыкка хәбәр итәргә.

3. Әлеге карар рәсми төстә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземдә калдырам.

**Республики Татарстан**
**Алексеевск муниципаль районының**
**Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге башкарма**
**комитеты җитәкчесе** **А.Ә.Җиһаншин**

СОВЕТ ПОДЛЕСНО-ШЕНТАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1605000819